**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2021 № 480

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (29 нчы кушымта), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган сатулар үткәрмичә генә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (30 нчы кушымта), муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (32 нче кушымта), муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (33 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
1.2. 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;
1.3. 2.14 пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче - унберенче абзацлар өстәргә:

«Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу максатларында :

1) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясенең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) кресло-колясканы файдаланып транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне аларның тормыш эшчәнлеге чикле булуын исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-ноктал шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемә кертүне;

6)Йөртүче- этне махсус укытуны раслый торган документ һәм аны бирү тәртибен раслау турында " 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының йөртүче-этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турындагы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документ булган очракта рөхсәт итү белән тәэмин итәргә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм әлеге пунктның 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары А. М.Шәрәфиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин